ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРГАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422971, Республика Татарстан,
Чистопольский район, с. Каргали,
ул. Чапаева, 10

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАРГАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422971, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Каргалы авылы,
Чапай урамы, 10

тел: 8(84342) 3-53-66, 3-54-01 e-mail: Karg.Ctp@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22 июнь 2023 ел № 19

Чистай муниципаль районының Каргалы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 20 декабрендәге «Чистай муниципаль районының Каргалы авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында»гы 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законга нигезләнеп, Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районының Каргалы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 20 декабрендәге «Чистай муниципаль районының Каргалы авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында»гы 11 номерлы карары белән расланган Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3, 1.4, 1.7 пунктларында, 1.5 пунктындагы «б» пунктчасында, 2.4 пунктындагы «д» пунктчасының беренче һәм икенче абзацларында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында яисә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге Чистай муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.

Каргалы авыл җирлеге башлыгы _______________ М.А. Заһидуллин